**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 6 и 11 Закона Республики Татарстан «О промышленной политике в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 апреля 2020 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 21 апреля 2016 года № 24-ЗРТ «О промышленной политике в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 78 (часть I); 2019, № 19 (часть I) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 6 дополнить пунктом $15^1$ следующего содержания:

«$15^1$) осуществляет в пределах своей компетенции контроль за выполнением инвесторами обязательств по специальному инвестиционному контракту в порядке, установленном Правительством Российской Федерации;»;

2) статью 11 изложить в следующей редакции:

«Статья 11. **Заключение специального инвестиционного контракта Республикой Татарстан**

1. Специальный инвестиционный контракт заключается с одной стороны инвестором, с другой стороны – совместно Российской Федерацией, и Республикой Татарстан, и муниципальным образованием Республики Татарстан в порядке, установленном законодательством Российской Федерации, по результатам проведения открытого или закрытого конкурсного отбора, за исключением случаев, установленных частью 15 статьи $18^3$ Федерального закона.

2. При заключении специального инвестиционного контракта от имени Республики Татарстан действует Президент Республики Татарстан.

3. Специальные инвестиционные контракты заключаются не позднее 31 декабря 2030 года на срок не более чем пятнадцать лет для реализации проектов, объем инвестиций по которым не превышает пятьдесят миллиардов рублей (без учета налога на добавленную стоимость), или не более чем двадцать лет для реализации проектов, объем инвестиций по которым превышает пятьдесят миллиардов рублей (без учета налога на добавленную стоимость).

4. Специальный инвестиционный контракт может быть заключен при условии, что на дату его заключения в нормативном правовом акте Республики Татарстан, являющейся стороной специального инвестиционного контракта, определены меры стимулирования деятельности в сфере промышленности, применяемые к инвестору, заключившему специальный инвестиционный контракт, и порядок их применения.

5. Специальный инвестиционный контракт не может быть заключен в случаях, если:

1) технология, на основе которой планируется осуществление производства промышленной продукции, не включена в перечень современных технологий;

2) проект не соответствует требованиям, установленным Федеральным законом или актом Правительства Российской Федерации;

3) объем капитальных вложений, запланированных в ходе выполнения специального инвестиционного контракта, меньше совокупного объема расходов и недополученных доходов бюджетов бюджетной системы Российской Федерации, образующихся в связи с применением мер стимулирования деятельности в сфере промышленности в отношении проекта, реализуемого в соответствии со специальным инвестиционным контрактом.

6. С даты заключения специального инвестиционного контракта и в течение срока его действия в отношении инвестора не применяются нормативные правовые акты Республики Татарстан, которые вступили в силу после даты заключения специального инвестиционного контракта и которые вводят ограничения и (или) запреты на реализацию прав, приобретенных или осуществляемых инвестором в целях выполнения специального инвестиционного контракта, при условии, что специальный порядок применения к инвестору положений нормативных правовых актов, регулирующих соответствующие отношения с участием инвестора, на случай их изменения был предусмотрен законодательством Республики Татарстан на дату заключения специального инвестиционного контракта.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Специальные инвестиционные контракты, заключенные с участием Республики Татарстан и действовавшие на день вступления в силу Федерального закона от 2 августа 2019 года № 290-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон «О промышленной политике в Российской Федерации» в части регулирования специальных инвестиционных контрактов», сохраняют свое

действие в соответствии с условиями этих специальных инвестиционных контрактов.

3. Изменение и расторжение специальных инвестиционных контрактов, заключенных с участием Республики Татарстан и действовавших на день вступления в силу Федерального закона от 2 августа 2019 года № 290-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон «О промышленной политике в Российской Федерации» в части регулирования специальных инвестиционных контрактов», осуществляются в порядке, действовавшем на день заключения таких специальных инвестиционных контрактов.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
БҮЛЕК ГОМУМИ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
07 мая 2020 года
№ 21-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:
«$15^1$) инвесторлар тарафыннан махсус инвестиция контракты буенча йөкләмәләрнең үтәлешен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә үз компетенциясе чикләрендә тикшереп торуны гамәлгә ашыра;»;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11 статья. **Татарстан Республикасы тарафыннан махсус инвестиция контракты төзү**

1. Махсус инвестиция контракты бер яктан – инвестор, икенче яктан – Россия Федерациясе, һәм Татарстан Республикасы, һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан бергә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Федераль законның $18^3$ статьясындагы 15 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, ачык яисә ябык конкурс сайлап алуын үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелә.
2. Махсус инвестиция контрактын төзегәндә Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Президенты эш йөртә.
3. Махсус инвестиция контрактлары, 2030 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, инвестицияләр күләме илле миллиард сумнан артмаган (өстәмә бәягә

салымны исәпкә алмыйча) проектларны гамәлгә ашыру өчен унбиш елдан да артык булмаган яисә инвестицияләр күләме илле миллиард сумнан артып киткән (өстәмә бәягә салымны исәпкә алмыйча) проектларны гамәлгә ашыру өчен егерме елдан да артык булмаган вакытка төзелә.

4. Махсус инвестиция контракты, аны төзү датасына әлеге контрактның бер ягы булган Татарстан Республикасының норматив хокукый актында махсус инвестиция контрактын төзегән инвесторга карата кулланыла торган сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чаралары һәм аларны куллану тәртибе билгеләнгән булу шарты үтәлгән очракта, төзелергә мөмкин.

5. Махсус инвестиция контракты түбәндәге очракларда төзелә алмый:

1) сәнәгать продукциясе җитештерүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган технология заманча технологияләр исемлегенә кертелмәгән булса;

2) проект Федераль законда яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте актында билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә;

3) махсус инвестиция контрактын үтәү барышында планлаштырылган капитал салулар күләме махсус инвестиция контракты нигезендә гамәлгә ашырыла торган проектка карата сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллануга бәйле рәвештә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының барлыкка килә торган чыгымнарының һәм алынмый калган керемнәренең җыелма күләменнән ким булса.

6. Махсус инвестиция контрактын төзү датасыннан алып һәм аның гамәлдә булу срогы дәвамында инвесторга карата махсус инвестиция контракты төзелгән датадан соң үз көченә кергән һәм махсус инвестиция контрактын үтәү максатларында инвестор тарафыннан сатып алынган яисә гамәлгә ашырыла торган хокукларны тормышка ашыруга чикләүләр һәм (яисә) тыюлар кертә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, әгәр инвестор катнашындагы тиешле мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар нигезләмәләре үзгәргән очракта аларны инвесторга карата куллануның махсус тәртибе махсус инвестиция контрактын төзү датасына Татарстан Республикасы законнарында каралган булса, кулланылмый.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы катнашында төзелгән һәм «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законга махсус инвестиция контрактларын җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 августындагы 290-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган махсус инвестиция контрактлары үзләренең гамәлдә булуларын әлеге махсус инвестиция контрактлары шартларына туры китереп дәвам итәләр.

3. Татарстан Республикасы катнашында төзелгән һәм «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» Федераль законга махсус инвестиция контрактларын җайга салу өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 августындагы 290-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә гамәлдә

булган махсус инвестиция контрактларын үзгәртү һәм өзү мондый махсус инвестиция контрактлары төзелгән көнгә гамәлдә булган тәртиптә башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 07 май
№ 21-ТРЗ